| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Әгерҗе шәһәре № 12-7

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 14 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре аукцион уздыру турында карар кабул итү датасына кадәр биш елдан да иртәрәк расланмаган Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль милектәге йә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен түбәндәге күләмдә билгеләргә:

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар составындагы җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган мондый җир кишәрлегенең кадастр хакының бер ярым проценты.

2. Татарстан Республикасы "Әгерҗе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге территориясендә Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль милектәге йә дәүләт милке чикләнмәгән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелмәгән категорияләр җирләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль закон нигезендә базар бәяләве нәтиҗәләре буенча билгеләнгән еллык аренда түләве күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев